РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ЮЛБАТСКИЙ СЕЛЬСКИЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422077, Республика Татарстан,
с. Юлбат, ул. Г.Тукая, 57
тел. (84362) 43-7-22

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ЮЛБАТ АВЫЛ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422077, Татарстан Республикасы,
Юлбат авылы, Г.Тукай урамы, 57 йорт
тел. (84362) 43-7-22

e-mail: Ulbat.Sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

01.04.2019 — № 23

Алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт
ителми торган биналарга, корылмаларга,
бүлмәләргә якын урыннарның схемасын раслау турында

1995 нче елның 22 нче ноябрендә кабул ителгән 171 нче номерлы «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнешен дәүләт тарафыннан тәртипкә салу турында» Федераль законның 16 нчы матдәсе нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 нче елның 27 нче декабрендә кабул ителгән 1425 нче номерлы «Алкогольле продукцияне ваклап сатарга ярамый торган гражданнарның күпләп җыелу урыннарын һәм югары дәрәҗәдәге куркыныч чыганаклары урнашу урыннарын Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан билгеләү, шулай ук алкогольле продукцияне ваклап сатарга ярамый торган кайбер оешмалар һәм объектлар янындагы чикләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләү турында» карары, ТР Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге Советының 2019 елның 25 нче мартында кабул ителгән 6 нчы номерлы “Алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган биналарга, корылмаларга, бүлмәләргә якын урыннар турында” карары нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. Алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган түбәндәге территорияләрнең схемаларын расларга:

1.1. МБОУ "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат төп гомуми белем бирү мәктәбе» янындагы территориянең схемасын;

1.2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Юлбат «Ромашка" балалар бакчасы янындагы территориянең схемасын;

1.3. Саба үзәкләштерелгән клуб системасының 24 нче филиалы (Юлбат авыл мәдәният йорты) һәм Юлбат фельдшерлык-акушерлык пункты янындагы территорияләренең;

1.4. Саба үзәкләштерелгән клуб системасының № 47 филиалы янындагы территориянең схемасын (Теніки авыл клубы);

1.5. Саба үзәкләштерелгән клуб системасының 54 нче филиалы янындагы территориянең схемасын (Йосыф-Алан авылы клубы) һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының «Ромашка «Юлбат балалар бакчасы филиалы - Йосыф-Алан балалар бакчасы».

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге башкарма комитетының «Алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган

биналарга, корылмаларга, бүлмәләргә якын урыннарның схемасын раслау турында» 2017 елның 1 декабрендәге 38а номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.


3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/ulbat, җирлекнең информацион стендларында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Юлбат авыл җирлеге башлыгы Т.Р.Шәмсиев


РАСЛАНГАН
Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Юлбат авыл башкарма комитетының
1 апрель 2019 ел № 23 карары белән

Алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган МБОУ " Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат төп гомуми белем бирү мәктәбе» янындагы территориянең схемасы




РАСЛАНГАН
Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Юлбат авыл башкарма комитетының
1 апрель 2019 ел № 23 карары белән

Алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Юлбат «Ромашка" балалар бакчасы янындагы территориянең схемасы




РАСЛАНГАН
Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Юлбат авыл башкарма комитетының
1 апрель 2019 ел № 23 карары белән

Алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган Саба үзәкләштерелгән клуб системасының 24 нче филиалы (Юлбат авыл мәдәният йорты) һәм Юлбат фельдшер-акушерлык пункты янындагы территорияләренең схемасы



РАСЛАНГАН
Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Юлбат авыл башкарма комитетының
1 апрель 2019 ел № 23 карары белән

Алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган Саба үзәкләштерелгән клуб системасының № 47 филиалы янындагы территориянең схемасын (Тенеки авыл клубы)



РАСЛАНГАН
Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Юлбат авыл башкарма комитетының
1 апрель 2019 ел № 23 карары белән

Алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган Саба үзәкләштерелгән клуб системасының 54 нче филиалы янындагы территориянең схемасы (Йосыф-Алан авылы клубы) һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының «Ромашка «Юлбат балалар бакчасы филиалы - Йосыф-Алан балалар бакчасы»

